**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Бертуган Бубилар исемендәге Иж-Бубый гомуми урта белем бирү мәктәбе**

# Тема: Мөхлисә Бубыйның педагогик эшчәнлеге.

Эшнең авторы: Альмукаева
Алинә Айрат кызы
Бертуган Бубилар исмендәге
Иж- Бубый гомуми урта
белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныф укучысы

2014ел

# Кереш

XX гасыр башында халыкны аң-белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту- тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Рәсәйдә дан-шөһрәт казанган татар мәдрәсәләре берничә генә. Шуларның берсе Иж-Бубый мәдрәсәсею Архив чыганакларына мәгълүм булганча, элеккеге Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж-Бубый мәдрәсәсе 1781 елда оеша. 1911 елда мәдрәсә патша хөкүмәте тарафыннан ябыла. 19 гасыр ахыры 20 гасыр башында танылган татар мәгърифәтчеләре Габдулла, Гобәйдулла, Мөхлисә Бубилар җитәкчелек иткән чорда ул мөселман конфессиональ мәгарифе үзәгенә әверелә. Монда беренче мөселман хатын-кызларын укыту башлана.

1907 елдан башлап,мәдрәсәдә аерым фәннәр  буларак гарәп, фарсы, төрек, рус, француз, арифметика, геометрия, физика, астрономия, география, ботаника, медицина,психология, педогогика алдынгы рус һәм Европа уку йортлары дәрәҗәсендә укытыла.

1908-1911 елларда мәдрәсәдә һәр елны 500 шәкерт белем ала. Биредә кызлар мәдрәсәсе дә эшләп килә. Ул Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйның кыз туганы Мөхлисә Бубый карамагында була. Мин Мөхлисә Бубыйның иҗади эшчәнлеген өйрәндем.

Иж-Бубый авылында туган як тарихын, мәдәниятен җирле гореф-гадәтләрен өйрәнүче музей эшли. Ул 1989 елда төзелә. Музейның эшчәнлеге балаларга патриотик, әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте бик зур.

Бүгенге көндә дә галимнәр, язучылар тарафыннан бу шәхесләрнең эшчәнлеге тирән өйрәнелә. 27-декабрь көнне Г. Камал исемендәге Дәүләт театрында  Ркаил Зәйдулланың "Үлеп яраттым" әсәре сәхнәләштерелде. Әсәрне сәхнәгә режисёр Илгиз Закиров куйды. Мөхлисә Буби ролен Дания Нурлы башкарды.

Бу спектакльне без, Иж- Бубый укучылары, Казанга барып карадык. Безгә укучыларга тагын бер кат җанлы тарих дәшә кебек. Укучылар мәдрәсә тормышын тагын бер кат күзалдыннан үткәрделәр.

Тарих җилләре исәләр бүген,<br>
Искә төшереп үткән елларны.

**“Үлчәүләргә сыймас олы хезмәт,**

**Мирас булып яши бүген дә...”**

Әгерже төбәге заманында гыйлем дөньясының зур мәгърифәт учагы булган Иж-Бубый мәдрәсәсе белән әле дә хаклы рәвештә горурлана. Авыл бүген дә әнә шул бер гасырлык тарихи ядкарьләр кайтавазында яши кебек.

Иж-Бубый тарихи чынбарлыгын әле дә саклый. Биредә йортлар да нәкъ элеккечә калган. Таш йортлар, кибет бинасы, борынгы мәчет, агач өйләр авылның борынгылыгын раслап тора.

Заманында Иж-Бубыйның данын еракларга тараткан уку йорты Иж-Бубый мәдрәсәсенең уңышларга ирешеп чәчәк ату елларында аның белән бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла һәм аларның сеңелләре Мөхлисә Бубыйлар җитәкчелек итә. Мәдрәсәне тәмамлап чыгучылар тирән фикерле, белемле, киң мәгълүматлы шәхесләр булып формалаша. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Бубый мәдрәсәсе зур үзгәрешләр кичерә. 1907 елдан башлап, мәдрәсәдә аерым фәннәр буларак гарәп, фарсы, төрек, рус, француз телләре, тарих, политэкономия, арифметика, геометрия, физика, астрономия, география, ботаника, медицина, психология, педагогика алдынгы рус һәм Европа уку йортлары дәрәҗәсендә укытыла. Фәлсәфә, логика, әхлак, Коръән, хәдис, ислам тарихы өйрәтелә. Укыту расписание буенча алып барыла, дәресләр үткәрү өчен бүлмәләр җиһазландырыла; уку елы ахырында имтиханнар уздырыла.

Россиянең төрле почмакларыннан мәдрәсәгә укырга яшьләр килә. 1908-1911 елларда биредә һәр елны 500 шәкерт белем ала.

Мәдрәсәдә һәр атнада әдәби, фәнни кичәләр уздырыла. Мәдрәсәнең бай китапханәсе, махсус җиһазландырылган спорт мәйданчыгы була.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең тарихы шактый зур һәм бай. Ул элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж-Бубый авылында 1781 елда оештырыла. Танылган мәгърифәтчеләрнең әтиләре Габделгалләм, Бубыйның алтынчы имамы. Әти-әниләре Бәдрелбанат абыстай белән Габделгалләм

хәзрәт Нигъмәтуллиннар заманы өчен белемле, алдынгы карашлы кешеләр була... Нигмәтуллиннар балаларына да ныклы белем бирәләр.

Патша хөкүмәте мөселман хатын-кызларына белем бирү турында кайгыртмаган. Шуңа күрә хатын-кызлар өчен беренче уку йортлары бары тик аерым кешеләр тарафыннан гына ачылган. Русларда мондый уку йортлары XIX гасырның икенче яртысында, татарларда исә хатын-кызлар мәктәпләре илле ел соңрак, ягъни XX гасыр башларында барлыкка килә. Татар хатын-кызлары өчен мәктәпләрнең иң беренчесе-элеккеге Вятка губернасы Иж-Бубый авылында була, аның белән Мөхлисә Нигмәтуллина - Буби идарә итә. Дөрес, бу рәсми дәүләт рөхсәте белән ачылган мәктәп булмаганлыктан, Мөхлисә ханымга, максатына ирешү өчен, бик күп каршылыкларны җимерергә туры килә. Мөхлисә абыстайны замандашлары зур гыйлемле, алдынгы карашлы, батыр йөрәкле һәм тәвәккәл татар галимә-хатыннарының берсе дип хәтерләренә сеңдереп калдырганнар, аеруча мәшһүр Бубый хатын-кызлар мәдрәсәсенең мөдире һәм мөгаллимәсе буларак, Русиядә яшәүче төрки халыклары арасында дан казанган ул. Әлбәттә хатын-кызлар өчен бу заманда мәдрәсә ачу, укыту җиңел эш булмаган. Хатын кызның хокуксыз, изелгән, уку, аралашу, җәмәгать эшләрендә катнашу хокукыннан мәхрүм ителгән заман бит бу.Иж-Бубыйда мәдрәсә ачылу никадәр кызларыбызга, туташларыбызга канатлар куя. Шунысы да бар, Бубыйлар кул куйган, шушы уку йортын тәмамлау турында таныкнәмә, мөгаллимлек хокукы биргән. Анда укытыла торган фәннәрнең күпкырлы, тирән булуы исә мәдрәсәне хаклы рәвештә югары уку йортына – академиягә тиңләгән..

Мөхлисә Буби 1869 елда Вятка губернасы, Сарапул өязе, Әгерҗе волостендагы Иж-Бубый авылында хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Тал чыбыктай зифа Мөхлисәне бик яшьли бер хәзрәткә кияүгә бирәләр. Ир дигәне бик эчкече булып чыга. Бер баласы булгач (кызы Мөнҗия), Минзәлә районында асрау булып торган бер хатын бала тапканда үлгәч, тәрбиягә алган Нәҗия исемле ятимә кызны да алып, иреннән аерылып кайта да, абыйсы Гобәйдулла һәм энесе Габдулла укыткан һәм җитәкчелек иткән

мәдрәсәдә кызлар сыйныфлары ачып, мөдирә булып, төрле фәннәрдән укыта башлый. Сыйныф бүлмәләре укыту-күрсәтмә әсбапләр һәм башка кирәк-яраклар белән әйбәт җиһазланган була. Мөхлисә абыстай мәктәбендә рус теле, татар теле-әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме, рәсем, матур язу һәм ислам дине сабагы укытыла.

Үз вакытында алдынгы уку йорты исәпләнгән бу мәдрәсәдә Себердән, Зайсаннан, Ташкенттан, Пржевальскидан, Пишпәктән (Бишкәк) һәм башка ерак җирләрдән килеп укучы хатын-кызлар күп булган. Татар мәгариф тарихында эз калдырган Рәсәй мәктәпләренең атказанган укытучысы Сара ханым Габбасия, Казан шәһәреннән Мәрьям ханым Зәйнетдин, Зәйнәб Максудия, мәшһүр мәгърифәтче, татар басма язуы өчен күп хезмәтләр күрсәткән, дәреслекләп язып калдырган Мөхәммәд әфәнде Идрисинең кызы Рабига ханым Идриси, Тукайның сөйгәне Зәйтүнә туташ Мәүледова , академик Диләрә Тумашеваның, шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның, Ләйлә садриларның әнкәләре һәм башкалар Мөхлисә абыстайдан тәгълим-тәрбия, гыйлем эстәгәннәр.

Оренбург шәһәрендә татар халкының мәдәнияте – тарихы өлкәсендә күзәтүләр, тикшеренү – эзләнүләр алып барган мөхтәрәмә Мәдинә ханым Рәхимколия язмаларының берсендә болай дип яза: “Аналы – кызлы Маһруй бинте Ибраһим вә Фатыйма бинте Гомәр, ирләреннән рөхсәт алып, һәркайсы икешәр-өчәр баласы белән Башкортстанның Слак (хәзерге Әлмәт районы) һәм Олы Кәркәле (хәзерге Миякә районы) авылларыннан 1909-1911 елларда Бубый мәдрәсәсенә укырга киләләр. Күкрәк балаларын карар өчен өлкәнрәк кызларын үзләре белән алып барганнар. Баерак укучы кызларга энҗе калфак, камзул чигеп, яшәү өчен азмы – күпме акча юнәтеп, Мөхлисә ханым мәдрәсәләрендә төпле белем алганнар”. Мөхлисәнең Бубыйга кайтуы милләт өчен файдага була дигән фикер белән килешмәскә һич мөмкин түгел.

1910-1911 нче елларда патша хакимиятләре татар җәдит мәктәп – мәдрәсәләрен аяусыз рәвештә яптыралар. 1912 елның 21 январендә Бубый мәдрәсәсе дә тар–мар ителеп, күп китап һәм кульязмаларны җыеп, урамда

яндырып, мөгаллим – мөгаллимәләрне кайсысын кулга алып, кайсысын сөргенгә җибәреп, укучыларны тараталар.

Шушы фаҗигале хәлләрдән соң Мөхлисә ханым Троицкий шәһәрендә (хәзерге Чиләбе өлкәсендә) Гәбделвәли (мәшһүр Ф. Аит, атаклы скрипач Мөхәммәд Яушның этисе) Яуш варисларында хезмәт итүче Габдрахман Әхмәр ачкан кызлар урта мәктәбендә укыта башлый. Төрле фәннәрдән сабак–дәрес бирә. Соңннан бу мәктәп Яушевлар исеменә күчә. Мөгаллимә-галимә Мөхлисә Бубыйның шөһрәте бөтен киң Русиягә тарала.

1917 нче елның маенда, Мәскәү каласында, Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда Мөхлисә ханымны Уфа шәһәрендә җирләшкән мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлыйлар.Олуг галимебез мөфти Ризаэтдин Фәхретдиновның уң кулы, ярдәмчесенә әверелә ул. Мәктәп музеендагы фотода Мөхлисә Буби унөч ир-ат арасында үз дәрәҗәсен белеп , якты нур бөркеп утырган бердән-бер хатын-кыз.. Ул ирләр сүзенә бик үк катышмаган төсле, әз генә читтәрәк утыра сыман, ләкин күренеп тора: чит-ят, үги бала түгел. Һич түгел. Шушы вакыйгаларның эчендә кайнавы, татар мәгърифәте өчен җан атып яшәве сизелеп тора. Тыйнак, сөйкемле, ягымлы ханым замандашлары арасында абруй казанган . Гадел, намуслы булуы хакында халыкта риваятьләр йөргән. Йөзәр чакрым юл үтеп, чарасыз, ярдәмгә мохтаҗ хатын-кызлар аның катына килеп егылган. Яклыйсын, гадел хөкем чыгарасын белеп, ышанып, инанып килгәннәр.
Ул Уфада башта Аксаков урамында абыйсы Гобәйдулла Бубыйның өендә, түбәнге катта яши. Олуг галимебез Ризаэтдин Фәхретдин җитәкчелегендә (әйтергә кирәк, ул Мөхлисә ханымга гомере буе бөек хөрмәт тойгысы саклаган), хатын – кызлар арасында зур оештыру, аңлату эшләре алып барып, җаны – тәне белән халыкка тәрбия бирү диңгезеннә чума, ул вакытта (1924 – 1927 елларда) Уфада нәшер ителгән “Ислам мәҗәлләсе” битләрендә мәкаләләрен бастыра, тәгълим - тәрбия өлкәсендә Фәхрелбанат Сөләймания (казый Габдулла Сөләйманинең әнисе), Гайшә абыстай (Җиһангир Абызгилдинның хатыны), Багбостан ханым, Ләбибә Хөсәен, Фатыйма

Аитларның уңай тәҗрибәләрен дәвам иттерә. Мөхлисә абыстайның исем– шәрифе – Русия мөселманнары арасыннан шытып-калкып чыккан дөньяда беренче һәм иң соңгы бердәнбер казыя-хатын буларак, аеруча дикъкатькә лаек. 1937 елның 19 ноябрь тарихында нигезсез гаепләнеп кулга алынып, бер ай дүрт көн дәвамында җәбер-золым шулпасын тулы мәгънәсендә татып, шул ук дәһшәтле елның 23 декабрь төнендә атып үтерелә. 1960 елның 25 маенда акланган.

Мөхлисә ханым үз кызы Мөнҗия белән бер яшьлек ятимә кызны (Нажияне), күз карасыдай карап үстерә, икесенә дә югары белем-мәгълүмат алырга ярдәм итә. Бик яшьли, фаҗигале рәвештә вафат булган Мөнҗия Троицкий шәһәрендә укытучылык эше белән шөгыльләнә. Нажия исә соңгы елларын Ташкентта яшәп, шунда вафат була.

Бүгенге көннәрдә без Мөхлисә абыстайның туганнары белән аралашып яшибез. Аның онык, оныкчыклары 22 сентябрьдә узган мәдрәсәнең 230 еллыгына багышланган тантаналарда кадерле кунаклар булдылар, Буа шәһәрендә яшәүче Мөхлисә Бубыйның тәрбияләп үстергән кызы Нажия белән туганлашучы Шәфкать Салих кызы белән хатлар алышабыз.

Мөхлисә Габделгаллләм кызы Бубый – татар хатын-кызларын агарту юлында гаҗәп зур эш башкарган шәхес. Күренекле галимәнең “Хатын – кызларга гаид” хезмәте алдагы фикерне дәлилләргә факт булып тора. Берникадәр шушы хезмәткә киңрәк тукталыйк. Гаид – гарәп сүзе – берәр нәрсәгә кайтучы, кайткан, бәйләнешле, караган дигән сүз. Шулай, мәгърифәтче – педагог Мөхлисә Бубый хатын-кызларга түбәндегеләрне киңәш итә.

“Җир йөзендә яшәүче кешеләрнең яртысы хатын-кызлар булуын истә тотып, әхлакый вазифалардан берничә генә сүз сөйләп узуны бурыч санадым”, - ди Мөхлисә Бубый.

Кешеләр чын мәгънәсендә кеше булсын өчен, алар күркәм холыклы булырга тиеш. Кеше үзенең әхлагын үзгәртергә, ягъни күркәм холыклы булырга теләсә, шөбһәсез, ул тәрбияле һәм әхлаклы була ала.

Күркәм холыкларның бүлемнәре күп, ләкин ул монда гаилә төзү өчен хатын-кызларыбызга иң кирәк булганнарыннан берничәсен әйтеп уза.
Җир йөзендәге милләтләрне тикшереп карасак, һәрбересе дә гаилә төзиләр һәм гаиләви тормыш белән яшиләр.
Гаилә төзү нәсел саклауга һәм кешеләрнең бәхетле булуына иң куәтле сәбәп булганлыктан, безнең ислам динебез дә гаилә төзүгә бик җаваплы каравыбызны таләп итә. Коръәни Кәримдә һәм Хәдис шәрифләрендә ир,хатын, бала һәм ата-аналар һәм кабиләләр хакында ачык әйтеп бирелгән. Гаиләләрнең төзек һәм тәртипле булуы бөтен яшәвебезнең,тормышыбызның төзек булуына сәбәп булып тора. Бер милләтнең урын тотуы һәм бәхетле булуы өчен ул милләтнең балалары һәм гаиләләренең тәртибияле булулары кирәк.

Гаиләләрнең тәрбиясез һәм әхлаксыз булулары милләтнең тамыры бозык һәм черек булуга беренче сәбәптер. Чөнки милләт шул гаиләләрдән төзелә һәм оеша – дип яза ул.

Шулай ук ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр турында да акыллы киңәшләрен бирергә онытмый галимә.” Гаилә дигән кечкенә оешма ир белән хатынның бергә яши башлавыннан барлыкка килә. Гаилә тәшкил итү (өйләнү) кешенең яшәү тарихында бик зур алмашыну булганга бик якшы тикшереп һәм уйлап эш йөртергә кирәк. Өйләнү – кешенең гомерлек иптәшлеккә берәүне алуы яки берәүнең баруы дигән сүз. Ислам дине бу хакта түбәндәге биш төрле шартка игътибар итәргә кушкан:
а) ир белән хатын бер-беренә әхлак һәм тәрбиядә тиң булсын;
б) ирнең алачак иптәшен тәрбия итәрлек байлыгы һәм икътисади җитешлелеге булсын;
в) боларның бере тәрбия җәһәтендә түбәнрәк булып чыкса, югарырак булганы түбәнрәк булганына күркәм юлдашлык итеп өйрәтергә тырышсын;
г) ир белән хатын яшь ягыннан бер-беренә якын булсын;
д) кушылачак ир белән хатын һәр икесе тышкы (төс) матурлыгыннан бигрәк, мәгънәви – рухи яктан (әдәп, тәрбия ягыннан) булган матурлыкны алда

тотарга тиеш. Төс никадәр матур булса да, әхлаксыз һәм тәрбиясез иптәштән бер файда да юк.

"Тиреслектә үскән яшел һәм матур чәчәкләргә алданмагыз", - дигән әйтем тәрбиясез һәм әхлаксыз матурлардан саклану хакында сөйли."

Мөхлисә Бубиның тагын бер әсәре "Ислам дөньясында хатыннар" дип атала. Бу мәкаләсендә ул телебезне саклау иң кирәкле бурычларның берсе икәнлеген ассызыклый. Үз телеңне яхшы белү, башка телләрне дә өйрәнү һәм һәркайсын уңышлы һәм урынлы куллану кебек хәзерге көндә бик актуаль проблемаларны күтәрә.

Шулай итеп, Русиядә мөселман хатын-кызлары өчен беренче уку йортларын нигезләгән, шуларда нәтиҗәле хезмәт иткән, татар һәм башка төрки халыкларның милли мәдәнияте өчен авыр көрәш елларын кичергән Мөхлисә ханым Бубиның исеме һич кенә дә онытылырга, тарих тузаннары эчендә күмелеп калырга тиеш түгел.

Чыгышымны Раушания апа Байтимерованың шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә: Гасырлар тирәнлегеннән ишетелә гүя бер өн-

Онытмагыз, онытмагыз, - оныклар бит сорар бер көн.

Тарих үзе оран сала – уяныгыз, уяныгыз!

Үткәннәрсез киләчәк юк, уйланыгыз, уйланыгыз!"

Кулланылган әдәбият:

1) Мәйдан,Чаллы әдәби-нәфис иҗтимагый журнал, 9/2011 сентябрь
2) А.Х. Махмутова «Лишь тебе, народ, служенье!» (стр.202-230)
3)Альта Махмутова «Пора и нам зажечь зарю свободы !» Казань Татарское книжное издательство, 2006 (стр.53-73)


# Өстәмәләр



Бертуган Бубилар яшәгән торак йорт бинасы.



Ул заманда эшләгән мәчет
1895 елда салынган



20 нче йөз башында Иж-Бубый авылы күренеше
Хатын кызлар мәдрәсәсе.



Мөхлисә Буби - Нигъмәтуллина






Кызлары

Нажия Мөнҗия




**Бубиларның гаиләсе. 2 рәт уңда Мөхлисә Буби?**



**1926 ел. Мөхлисә Буби дин әһелләре арасында.**



**Нажия һәм Кыям Бигашевларның оныгы Рәйсә апа  һәм Бубилар тарихын өйрәнүче галим Раиф Мәрданов (2011 ел)**

## *«Хатын кызларга гаид»* **Мөхлисә Буби**

Җир йөзендә яшәүче кешеләрнең яртысы хатың кызлар булуын истә тотып. әхлакый вазифалардан берничә генә сүз сөйләп узуны бурыч санадым.

Гаилә төзү, нәсел саклау һәм кешеләрнең бәхетле булуына иң куәтле сәбәп булганлыктан, безнең ислам динебез дә гаилә төзүгә бик җаваплы каравыбызны таләп итә. Гаиләләрнең төзек һәм тәртипле булуы, бөтен яшәвебезнең, тормышыбызның төзек булуына сәбәп булып тора.

Гаилә дигән кечкенә оешма ир белән хатынның бергә яши башлавыннан барлыкка килә. Гаилә тәшкил итү - кешенең гомерлек иптәшлеккә берәүне алуы яки баруы, ислам дине бу хакта биш төрле шартка игътибар итәргә кушкан:

Ир белән хатын бер-беренә әхлак һәм тәрбиядә тиң булсын , ирнең алачак иптәшен тәрбия итәрлек байлыгы һәм икътисади җитешлеге булсын, боларның бере тәрбия җәһәтендә түбәнрәк булып чыкса, югарырак булганы түбәнрәк булганына күркм юлдашлык итеп өйрәтергә тырышсын, ир белән хатын яше ягыннан бер-берсенә якын булсын, кушылачак ир белән хатын һәр икесе тышкы төс матурлыгыннан бигрәк, мәгънәви, рухи яктан (әдәп, тәрбия ягыннан) булган матурлыкны алда тотарга тиеш. Төс ни кадәр матур булса да, әхлаксыз һәм тәрбиясез иптәштән бер файда да юк. «Тирեслектә үскән яшел һәм матур чәчәкләргә алданмагыз» - дигән әйтем тәрбиясез һәм әхлаксыз матурлардан саклану турында сөйли.

Ир белән хатынның бер- берсенә каршы әхлакый бурычларының иң кирәклесе дүрттер:

1. Сәдәкать (Бер-берeңә ышанычлы булу) – Ир кеше йортның тышында хезмәт итеп, гаиләсен туйдырырга тиеш булган кебек хатынга да йорт эчендәге эшләрне үтәп, гаилә әгъзәләрен тәрбияләргә туры килә, әгәр ир белән хатын икесе бер әгъза булып, берсе икенчесен кайгыртса һәм күңелләре бер булса, менә шул гаилә бәхетле була һәм рәхәт яши. Чөнки болай булганда берсе икенчесеннән шөбһәләнми, камил бер-беренә ышана һәм икесе дә җаннары рәхәт булып мәхәббәт белән гомер кичерүгә сәбәп булла, әгәр дә боларның арасында аз гына хыянәт булса, ир белән хатынның арасы бозылуга сәбәп була. Никахның төп мәгънәсе дә бер-берeңә рәхәтлек китерүдән, килешеп яшәүдән гыйбәрәттер.
2. Миният (ышаныч. тынычлык) әгәр ир белән хатын бер-берсенә ышанычлы булмаса, бердәмлек, мәхәббәт урнаша алмый
3. Хәтер саклашу. – ир белән хатын бер-берсенә игътибарлы булсын.
4. Могавәнәт (ярдәмләшү, булышлык ) Никах дигән килешүнең иң кадерле җимеше дә ир белән хатынның бер-беренә җиңеллек кылулары

Хатын белән ирнең бер- берсенең алдында аерым бурычлары да бар.

Ирнең хатынга эшләргә тиеш булган бурычлары: беренчесе: табигать ягыннан ир хатыннан куәтле булып яратылган. Шуның өчен ирнең өстенә күп кенә авыр эшләр йөкләнә. Ир хатынның ашау - эчүен, кием салымын, тора торган урынын тәэмин итәргә тиеш. Боларны эшли алмаганда, шәригать буенча һәм рәсми рәвештә өйләнүдә файда юк.

Икенчесе: Ир мәңгелек иптәшенең намусын һәм вөҗүден ( вөҗүд –гәүдә, яшәеш дигән сүз) үз намусы һәм вөҗүде кебек күреп сакларга, гүзәл нәсихәтләрдә булырга һәм Аллаһы тәгаләнең «хатыннарга күркәм мөгалләмәдә булыгыз» дигән сүзләрен онытмаска тиеш. Нәзәкать һәм хис ягыннан хатыннар ирләрдән артыграк һәм дә хатыннарга яшәү өчен кирәк булган мал биру дә ирләр өстендәдер.

Хатынның иргә эшләргә тиешле бурычлары: 1) Хатыннар ирләре тапкан ашау –эчү һәм башка кием һәм йорт нәрсәләрен исраф итмичә, ватмый, чәчми саклап тотарга тиеш. Эшләп тапкан акчаны кирәксез кием-салымга һәм башка бик хәҗәт булмаган урыннарга тоту – хатыннарның тәрбиясезлеге саналып, идарәсез, йорт тота белмәгән хатын хисапланадыр, бу эш шәригать һәм халык каршында начар бер сыйфат. Күбесенчә андый хатыннарның гомерләре фәкыйрь һәм мохтаҗлыкта үтә һәм бөтен гаиләне бәхетсез итүгә сәбәп була. Матди яктан ир хатынның ярдәмчесе. Шуларны уйлап, хатын да иренә чын иптәш булып, күңеле ирендә һәм гаиләсендә генә булырга тиеш. 2) Ир белән хатын арасында аз гына бердәмлек киту белән аерылуны сорамаска, чөнки бу күңелсез бер фаҗига. Мондый вакытта ике араны төзәтерлек туганнарга мөрәҗәгать итәргә яисә шундый сәбәпләр эзләргә кирәктер.

Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы ихтыяҗга карап йөри.. хатыннарга йөкләнә торган авыр түгел, әмма үзләре бик кирәкле вә файдалы хезмәтләр бар. Шул хезмәтләрне үтәү – алар өстенә төшкән бер бурыч. **<u>Гаиләнең иң олы бурычы – тәртипле бала тәрбияләү.</u>**

Безнең хатын кызларыбызга төшкән бурычларның берсе – үзебезнең гореф гадәтләребезне саклау булса, икенчесе – тел саклау. Бүгенге көндә безнең юлга салынган, бик яхшы һәм җитеш телебез бар. Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торышлы түгел. Шулай да бөтенләй кирәкми һәм килешми торган урыннарда рус сүзе яисә башка чит тел кулланыла торган очраклар күп.

Халкыбыз русча белсен, кулыннан килсә башка телләр белән дә хәбәрдар булсын. әмма үз сүзебез арасында урынлы- урынсыз, кирәкле- кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми. Үз өендә бик күп русча сүз катнаштырып сөйләп тә, руска йомышы төшкәч, тылмач аркылы сөйләү һөнәр булмаска кирәк. Бүгенге көнге хатыннарның, аналарның беренче вазифалары – үзләренең ана телләрен саклау, онытмау, өй эчендәге тел хуҗасы булып тору.

## Мөхлисә Бубый : “Ислам дөньясында хатыннар”.

**Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы ихтыяҗга карап йөри. Дөньяда шундый урыннар һәм шундый вакытлар була – башка бер урында һәм башка бер заманда санга алынмый торган бер хезмәт бик кирәкле вә бик файдалы булып чыгадыр.**

**Безнең шушы өлкәбездә вә шушы көннәребездә хатыннарга йөкләнә торган авыр түгел, әмма үзләре бик кирәкле вә файдалы хезмәтләр бар. Шул хемәтләрне үтәү алар өстенә төшкән бер бурыч. Әмма бурычны түләү чиксез рәвештә садакалар өләшүгә күрә дә файдалы вә саваплы булуында шөбһә юк.**

**Ул бурычларның берсе – үзебезнең дини гадәтләребезне вә рәсемнәребезне саклаудыр.**

**Безнең хатын-кызларыбызга йөкләнә торган бурычларның икенчесе – тел саклау. Бүгенге көндә безнең юлга салынган һәм дөньявый йомыш-ларын гына түгел, хәтта дин вә гыйлем турындагы йомышларыбызны үтәрлек үз арабызда куллана торган телебез бар.**

**Гәрчә арада читләрдән кергән сүзләр күп булса да, ул сүзләр инде үз малыбыз булып киткән, төркичә булып саналу тиешле күрелгән. Димәк, бик яхшы һәм җитеш телебез бар. Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торырлык түгел. Әле шулай була торып, авылларда кирәгеннән артык, хәтта бөтенләй кирәкми һәм килешми торган урыннарда рус сүзе кулланыла башлаганлыгы күреләдер.**

**Бер кеше: “Дим буенда “.... “авылында булдым. Рус мәктәплә-рендә укып чыккан ике яшь егет озын вакыт сөйләшеп утырдылар. Сүзләре бөтенләй нур кичә дисәм, урынлы. Шул урында ике авыл агаеның сөйләшеп утырганда ватып-җимереп катнаштырган русча сүзләре өчтән бере булды дисәм, арттырып сөйләү булмас”, - диде.**

**Халкыбыз русча белсен, кулыннан килсә, башка телләр белән дә таныш, хәбәрдар булсын, белү бик кирәк, әмма үз сүзебез арасында урынлы- урынсыз, кирәкле-кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми.**

**Мондый эш үз телебез юлга салынмас борын ярыйдыр иде, хәтта инде үз ана теле мәктәпләрдә генә түгел, хөкем йортларында һәм хөкүмәт даирәләрендә рәсми тел булып йөртелә башлады. Инде бик тәртипле телебез бар. Моннан соң бу эш ярамый.**

**Үзенең өендә бик күп русча сүз катнаштырып сөйләп тә, руска йомышы төшкәч, тылмач аркылы сөйләү һөнәр булмаса кирәк.**

**Бу көнге безнең бу өлкәдәге , бигрәк тә, башкорт хатыннарының беренче вазыйфалары – үзләренең ана телләрен саклау, оныттырмау, өй эчендә тел хуҗасы булып торудыр. Бу хезмәт аның өчен авыр түгел.**

**Дөньяда булган һәр төрле кавемнәрнең телләрен саклаучылар шул кавемнәрнең аналары һәм телләре булган хәлдә, безнең халкыбызның телләрен саклаучылар да үзләренең аналары һәм хатыннары булырга тиешле. Безнең халкыбызның аналары, хатыннары зирәклек тугрысында башкалардан ким түгел.**